СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕҖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**Сеҗе авыл җирлеге Советы**
**карары**

**« 28 » декабрь 2023 ел** **№ 108**

**«Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләме һәм шартлары турында» 2019 елның 13 маендагы 90 номерлы Сеҗе авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (29.12.2021 № 46, 30.09.2022 № 68, 19.12.22 № 77 үзгәрешләр белән)**

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, «Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына 1 нче кушымтага үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 13 сентябрендәге 987 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, урынбасарлары, аудиторлары, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатлар, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затлары хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге уставы нигезендә, Сеҗе авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләме һәм шартлары турында» 2019 елның 13 маендагы 90 номерлы Сеҗе авыл җирлеге Советы карарына (29.12.2021 №46, 30.09.2022 №68, 19.12.22 №77 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Аларга бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагыла торган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге хезмәткәрләренең хезмәт хакы турында нигезләмәнең 4 абзацын (3 нче кушымта) түбәндәге абзацлар белән тулыландырырга:

"Тариф ставкасыннан (окладтан) тыш, хезмәткәрләргә түбәндәге өстәмәләр һәм түләүләр билгеләнә:

Эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык тариф ставкасының 25 процентыннан артмаган күләмдә айлык өстәмә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Р. В. Хәмидуллин

СОВЕТ СИЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ